**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Үрнәк авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

«08» ноябрь 2022 ел № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 8 ноябрендә узган:

«Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, тол хатыннардан кала, балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү максатыннан су челтәрләрен ремонтлау, карап тоту өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;
- Үрнәк авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком, кулланылган асфальт җәю (сатып алу, ташу, җәю), чокырларны ремонтлау (юеш коелган асфальт);
- Үрнәк авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;
- авыл җирлеге торак пунктлары, урамнарны, территорияләрне, Үрнәк авылы зиратын төзекләндерү һәм сезонлы тоту (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үләнне чабу);
- Үрнәк авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу . мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 89 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 64 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 54 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 10 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Үрнәк авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Признать принятым решение по вопросу:

«Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, тол хатыннардан кала, балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү максатыннан су челтәрләрен ремонтлау, карап тоту өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;

- Үрнәк авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком, кулланылган асфальт җәю (сатып алу, ташу, җәю), чокырларны ремонтлау (юеш коелган асфальт);

- Үрнәк авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;

- авыл җирлеге торак пунктлары, урамнарны, территорияләрне, Үрнәк авылы зиратын төзекләндерү һәм сезонлы тоту (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үләнне чабу);

- Үрнәк авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны таныргa.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Үрнәк авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Л.И. Кашапова

Киекле авыл җирлеге башлыгы: Л.И. Кашапова